| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

«19» марта 2021 с. Тюлячи № 123

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 декабрендәге 495 номерлы «2021 елга Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

МКУ«Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»нең 2020 елның 22 декабрендәге 394 хатын карап, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 02 июлендәге 546 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 декабрендәге 495 номерлы «2021 елга Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» карарына (27.01.2021 ел № 23 карар редакциясендә), түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«- 2021 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен керткәндә ташламалар карала торган затлар исемлеге, 4 номерлы кушымта нигезендә

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 12 ноябрендәге
495 номерлы карарына
4 номерлы кушымта

2021 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен керткәндә ташламалар карала торган затлар исемлеге

1. Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве алынмый:

- инвалид балаларны, ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, шулай ук туберкулез интоксикациясе булган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен;

- өч һәм аннан күбрәк балалары булган ата-аналар өчен мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвен 50 процентка киметергә;

- ата-аналарның берсе 1 инвалид булган, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче ике бала тәрбияләүче гаиләләрдән;

- ата-аналарның берсе 1 инвалид булган, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче бер бала тәрбияләүче, һәм җан башына уртача керем яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләрдән.

2. Муниципаль белем бирү учреждениеләрендә балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен түләүгә ташлама ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы һәм гаиләнең ташламага хокукы булуын раслаучы документлар нигезендә бирелә.

3. Гаиләнең берничә ташламага хокукы булганда, ата-ана (законлы вәкилләр) сайлау буенча бер ташламаны гына кулланылырга тиеш.

4. Әлеге исемлекнең 1 пунктында күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын алу хокукына ия мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында салым органының белешмәсен бирергә тиеш.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин